СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Дубъязы, улица Ленина, д.28

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ДӨБЬЯЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дөбьяз авылы, Ленин урамы, 28

тел./факс 8(8436561-286, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**15 мая 2023г.** **№66**

## Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә, Дөбьяз авыл җирлеге Советы:

1. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән соң өч еллык срокның тәмамлануы яки аны гражданлык процессуаль законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә үлгән дип игълан ителүе, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаса, яки варислар мирас алудан читләштерелсә, яки варисларның мирас алу хокукы булмаса, яки аларның барысы да мирас алудан баш тартса, һәм аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) салым салу объекты булган милеккә милек хокукы туктатылган көннән алып өч еллык срокның тәмамлануы;

4) җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү буенча бурыч барлыкка килгән көннән алып өч еллык срок тәмамлану.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбьяз авыл җирлегенең 02.11.2019 ел, №145 «Җирле салымнар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре, әлеге салымнар буенча штрафлар, пенялар турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биекту муниципаль районы сайтының авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан республикасының норматив хокукый рәсми сайтында урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге Карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла

5. Әлеге карарның үтәлешен үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Галиуллин